**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет
муниципального образования
«поселок городского типа
Актюбинский» Азнакаевского
муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы
«Актүбә шәһәр тибындагы поселок»
муниципаль берәмлеге башкарма
комитеты**

ул. Губкина, д. 24, п.г.т.
Актюбинский, Азнакаевский
муниципальный район, 423304
тел. (факс): (85592) 3-16-63
E-mail: Svetlana.Strukova@tatar.ru

Губкин урамы, 24 йорт, Актүбә ш.т.п.,
Азнакай муниципаль районы, 423304
тел. (факс): (85592) 3-16-63
E-mail: Svetlana.Strukova@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«26» гыйнвар 2021 ел № 6

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Актүбә шәһәр тибындагы поселок Советының 2013 елның 30 декабрендәге 38 номерлы карары белән расланган,Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү турында (24.08.2015 №22, 30.09.2016 №15, 05.09.2017 №16, 02.07.2018 №30, 28.12.2018 №71, 15.03.2019 №11, 30.01.2020 №5 карарлар редакциясендә)

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 8, 33 статьяларына һәм 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга таянып, «Актүбә шәһәр тибындагы поселок» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясенең 2021 елның 20 гыйнварындагы бәяләмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының "Актүбә шәһәр тибындагы поселок" муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карар итә:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Актүбә шәһәр тибындагы поселок Советының 2013 елның 30 декабрендәге 38 номерлы (24.08.2015 №22, 30.09.2016 №15, 05.09.2017 №16, 02.07.2018 №30, 28.12.2018 №71, 15.03.2019 №11, 30.01.2020 №5 карарлар редакциясендә) карары белән расланган,Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Актүбә шәһәр тибындагы поселок» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын әзерләүгә керешергә:

1.1. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең текст өлешен Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына туры китерергә.

1.2. Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасында:

- Татарстан Республикасы, Азнакай муниципаль районы, Актүбә ш.т. п. адресы буенча урнашкан 16:02:240118:902 кадастр номерлы 4 160 кв.м. мәйданлы җир кишәрлеге өчен территориаль зонаны СХУ зонасыннан ял итү, спорт, табигый-танып белү туризмы һәм санатор-курорт дәвалавы зонасына РЗ үзгәртергә.

- Татарстан Республикасы, Азнакай муниципаль районы, «Актүбә» ҖЧҖ, 64 нче номерлы сөрүлек, адресы буенча урнашкан 16:02:240115:10 кадастр номерлы 548 613 кв.м. мәйданлы җир кишәрлеге өчен территориаль зонаны махсус билгеләнештәге яшелләндерү зонасыннан СН2 бакчачылык һәм дача участокларының яңа төзелә торган Р4 зонасына үзгәртергә.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының "Актүбә шәһәр тибындагы поселок" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү тәртибен һәм вакытларын билгеләргә (кушымта).

3. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче И.И. Мөхәмәтҗанов

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Актүбә шәһәр тибындагы поселок» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карарына кушымта
«26» гыйнвар 2021 ел № 6

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Актүбә шәһәр тибындагы поселок» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект әзерләү эшләрен үткәрү тәртибе һәм сроклары**

| № | Эшләр уздыру тәртибе | Эшләрне башкару вакыты |
|---|---|---|
| 1. | Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект әзерләү эшләрен оештыру. | 2021 елның I кварталы |
| 2.<br><br>2.1.<br><br>2.2.<br><br>2.3. | Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү һәм килештерү.<br>Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең текст өлешен Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына туры китерү.<br>Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең картографик материалларына үзгәрешләр кертү.<br>Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны килештерүдә катнашучы хезмәтләр һәм ведомстволар кисәтүләренә шәрехләр әзерләү. | 2021 елның I кварталы |
| 3.<br><br>3.1.<br>3.2.<br><br>3.3.<br><br>3.4. | Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект буенча фикер алышу.<br>Ачык тыңлаулар үткәрү.<br>Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында закон проектына үзгәрешләр кертү.<br>Күрсәтелгән проектны һәм аңа карата мәҗбүри кушымталарны (беркетмә һәм ачык тыңлаулар бәяләмәсе) Башкарма комитет җитәкчесенә тапшыру.<br>Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселок» муниципаль берәмлеге башлыгына җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә һәм аңа карата мәҗбүри кушымталарга үзгәрешләр кертү турында (беркетмә һәм ачык тыңлаулар бәяләмәсе) проектны Азнакай муниципаль районының Актүбә шәһәр тибындагы поселок Советына раслау яисә кире кагу турында карар кабул итү өчен, аны кабат тапшыру датасын күрсәтеп, эшләп бетерергә җибәрү. | 2021 елның I кварталы |